ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруның актуаль мәсьәләләре хакында

«Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруның актуаль мәсьәләләре хакында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе рәисе Л.Р. Фазлыеваның һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе А.А. Чубаровның мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе рәисе Л.Р. Фазлыеваның һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе А.А. Чубаровның мәгълүматын игътибарга алырга.

2. «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының актуальлеген, аның нормаларын үтәүнең реаль булуын, хокук кулланучылар тарафыннан төрле мәгънәдә аңлашыла торган каршылыклар һәм нормалар булмавын билгеләп үтәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында» 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыруны мониторинглауны дәвам итәргә.

4. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Махсус хәрби операция ветераннарын балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре итеп беркетү эшен активлаштыру буенча чаралар күрергә.

4.2. Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләрен ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, ирегеннән мәхрүм ителмичә хөкем ителгән, ябык типтагы махсус уку йортыннан кайткан һәр балигъ булмаганга беркетергә.

4.3. 2025 елда «Татарстан Республикасы балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе – 2025» балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре арасында республика конкурсын үткәрергә.

4.4. Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренә һәм балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренә кандидатларга мәгълүмати ярдәм күрсәтүне һәм консультация ярдәмен тәэмин итәргә.

4.5. Карала торган өлкәдә законнарны камилләштерүгә бәйле мәсьәләләрне өстәмә рәвештә законнар белән җайга салу зарурлыгы булганда, тиешле тәкъдимнәр әзерләргә һәм аларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына тапшырырга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

5.1. Җәмәгать тәрбиячеләренә матди ярдәм һәм аларны кызыксындыру, аларны бүләкләү чараларына Татарстан Республикасы бюджетында акчалар карарга.

5.2. Остазларны, шул исәптән җәмәгать тәрбиячеләрен, матди һәм матди булмаган яктан кызыксындыру, аларны бүләкләү тәртибен билгели торган норматив хокукый акт кабул итү турындагы мәсьәләне карарга.

6. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары белән хезмәттәшлектә балигъ булмаганнар тарафыннан җәмгыятькә каршы гамәлләр кылу очракларын булдырмау максатларында балигъ булмаганнарны актив социаль тормышка җәлеп итүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

7.1. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләргә махсус хәрби операция ветераннарын балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре итеп беркетү мәсьәләләре буенча максималь ярдәм күрсәтергә.

7.2. Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләрен бүләкләү эшен дәвам итәргә, аларны акчалата бүләкләү мөмкинлеген карарга.

8. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

8.1. Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре эшчәнлеге турындагы материалларны массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштыруга аерым игътибар бирергә.

8.2. Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре тарафыннан үткәрелә торган чараларга, шулай ук «Татарстан Республикасы балигъ булмаганнарның иң яхшы җәмәгать тәрбиячесе – 2025» балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре арасында республика конкурсы чараларына мәгълүмати ярдәм күрсәтүне тәэмин итәргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 10 июле
№ 86-VII ДСП